Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының
Иске  Суркино авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ № 7

20 август 2021  ел

Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино
авылы башкарма комитетының кайбер
карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Әлмәт шәһәр прокуратурасы бәяләмәсен һәм программаны гамәлгә ашыруга финанслау чыганаклары булмау турында Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы бәяләмәсен, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының законнарга норматив хокукый актларны туры китерү турындагы телдән күрсәтмәсен карап,

Иске Суркино авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авылы башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 19 февралендәге 3 номерлы

- «Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авылы башкарма комитетының «2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 19 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 16 мартындагы 5 номерлы.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Суркино авылы, Үзәк урам, 77 нче йорт; Яңа Суркино авылы, Үзәк урам, 12а йорты торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Суркино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе — Н.В. Леонтьев